33

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № I-4**

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 23 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының даими комиссияләрен төзү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 32 статьялары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXVI-2 номерлы карары белән расланган Совет Регламентының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының түбәндәге даими комиссияләрен төзергә:

- бюджет, финанс, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссия;

транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссия;

- социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссия;

- экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссия;

- законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссия.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов

Р.07-3577/02
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
СОВЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНН 1634005057